Татарстан яшьләре

№2

(8880)

ПӘНҖЕШӘМБЕ

6 гыйнвар, 1994 ел

Бәясе килешү буенча.

* ЯШЬЛӘРНЕН ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ * 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЫННАН БИРЛЕ ЧЫГА *

Агыйдел бозларында Яңа ел утлары җемелди

(Репортаж)

Татарстаныбызга янә Яңа ел килеп керде. Башкалада гына түгел, районнарда да аны көтеп алдылар. Аны илебез түренә кем озатты дисез? Әлбәттә, кояш чыгышына якын урнашкан Актаныш ягы.

Ә хәзер бер мизгелгә генә күз алдыгызга китереп карагыз әле: каршыгыздагы зур гына мәйданда Агыйдел елгасыннан электр пычкысы белән квадратлап кисеп алынган үтә күренмәле боз плиталәр хасил булыр. Алардан кеше бискләгендә өелгән лабиринт стеналар, пыяла сыман сәхнә мәйданчыгы, үтә күренмәле зур гына мич барлыкка килер. Шунда ук күзләрегез дистәләгән әкият геройлары - Урман җәнлекләренең кардан әвәләп, су белән катырып, үз төсләренә буяп ясалган сыннарына юлыгар. Әлбәттә, дәү тәүдәле Кыш бабай белән Кар кызы да булыр анда. Ә икенче бер кырыйда бик биек боз тавы - бала-чаганың мәш килгән урынын күрерсез. Бу - мәһабәт боз шәһәрчеге. Ә аңа өч яктан да пәтиә таңдап бизәкләп эшләнгән бәллүр капкалар аша керерсез. Алар да шул ук Агыйдел бозыннан ясалган. Әмма Яңа елга җитәргә уч көн кала районның хакимият башлыгы Таһир Әхмәев "казып чыгарган" боз шәһәрчеге идеясе районнары бер генә осима җитәкчесенә дә чанга айбар нәрсә булып тоелмаган. 31 декабрьдә кичкы "боз илен"ә колхоз-совхозлардан килгән бизәкле, кыңгыраулы "тройка" атлар килеп кергәч, мәйданга шат Актаныш халкы һәм районның сәнгать осталары тулгач, моның кыял гына булмавына барысы да ышанды.

"Боз иле"нә иске елның соңгы көнен озатырга килүчеләрнең исәбе-хисабе юк. Ә бит тышта 30 градус салкын. Карты да, яше дә үз алдына биесә бии, әмма берәү дә таралырга ашыкмый. Якында гына шашлык пешә, аны башласаң, ут җылысы янына уэарга була, йә бала-чага янына тауга менеп шуып төшәсең. Сәхнәдә бер-бер артлы колхоз-совхоз кунаклары, Кыш бабай һәм кар кызлары, район җитәкчеләре сүз ала, җыр-бию башланып китә. Нар агларга утырып әле яңа гына язылышу сараенннан килгән яшьләр дә бирелә. Мондый тантаналарны бары тик кыңгыраулы атлар белән генә үткәрү идеясе дә администрация башлыгыныкы. Борынгы йолаларны яңарту эшен беренче булып "Үзәк" колхозы рәисе Равил Камильянов үз өстенә алган...

Курантлар 12не сугып, шампанныр атылгач, бәхетләр теләп бокаллар күтәрелгәч тә Яңа елның беренче сәгатьләре халыкны шушы шәһәрчеккә китерде. Район хакиме төнге 2 дә үзе дә чыкты бирегә. Мәйдан нәкъ көндезгечә төрле: бала-чагасы бала-чага урынында, өлкәннәре күмәк җырбиюгә кушылып күңел ача. Уртадагы зур учак халыкны үз әйләнәсенә җыйган. Кыш бабай, Кар кызлары да бәйрәм үзәгендә, хәтта шашлык пешерүчеләр дә көн буе эшләп армаган.

Мин Актанышның үзендә генә дә төрле төстәге электр лампаларыннан елык-елык килеп торучы 10нан артык чыршыны санадым. Очларындагы йолдыз йә ай да бер сүнә, бер яна. Гүзәл майзара! Шәһәрдәгедән һич тә ким түгел.

Әлфия САМАТ.

Укыдыгызмы? Ишеттегезме?

Мәскүнең 29 яшьлек бер кешесе, чәч сатып алу турындагы рекламаны күреп, хатынын чәчен кырдырырга кыстый башлаган. Әмма хатын риза булмаган. Сүз арты сүз чыгып, ир белән хатын бик каты талаша башлаганнар. Ярсыган ир, хатынын чәченнән элэктереп алып, өстәлгә бәйләп салган һәм аның башын пеләш калдырып кырып ташлаган.

Петропавловск-Камчатский шәһәре читендә кәтү булып йөрүче сукбай этләр чын бәлагә әверелгән. Шәһәр хастаханәләреннән алынган мәгълүматларга караганда, узган ел башыннан бирле 400 кеше эт тешләү аркасында дәваланырга мәҗбүр булган. Петропавловск медиклары эт елы дип тормаганнар, ә аларны юк итү буенча кичектергесез чара күрүне таләп итеп шәһәр властьларына мөрәҗәгать белән чыкканнар.

Вологда шәһәрендә яшертен рәвештә корал ясап сатучылар төркеме кулга алынган. Тентү вакытында уналты автомат һәм пистолет табылган.

Яңа елга кадәр ике көн кала совет комик киносының популяр артисты Фрунзик Мкртчян вафат булды. Ул тамашачыларга "Айболит-66", "Кавказская пленница", "Мимино" һ.б. бик күп фильмнар буенча таныш.

Укучыларыбыз игътибарына узган 1993 елда шигъри көлә белүчеләр бәйгесенә (ШКББ) килгән күпсанлы шигырьләрнең берничәсен тәкъдим итәбез. Бу шигырьләр 1994 елда да актуаль яңгырый һәм Яңа елда да тапкыр телле укучыларыбызның иҗат чишмәсе, шат, саекмас. Яңа елга елмаеп, көлеп керик әле!

ШКББ

Шигъри көлә белүчеләр бәйгесе

Китә казлар...

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Казанга;
Гомеребез туры килде
Каһәрле дә заманга.

Китә казлар, китә казлар,
Китә Чабаксарларга;
Пенсиягә генә чаклы
Ничек җан асырарга?!

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Шыкмайга.
Такыр булгачтын кесәләр
Буйлар җитми ит, майга.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Чаллыга;
Гомер җыйган акча җитми
Чалбар-күлмәк алырга.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Кенәргә;
Барлы-юклы акча "туңды"
Саклыкта - кенәгәдә.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Көңгергә;
Нефть өсләрендә яшәп,
Бензин да юк йөрергә.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Әлмәткә;
Түләп бетермәслек булып
Керен баттык әҗәткә.

Китә казлар, китә казлар,
Китә казлар Шөгергә;
Күпме туры килер безгә
Нужа чигеп йөрергә?!

Әзһәр ГАБИДИ.
Сарман районы, Чукмарлы авылы.

Наданлык көчле

("Ваша киска купила бы "вискас". Телерекламадан)

Тормыш эмен, яшәү рәвен
Һич кенә дә белмибез.
Телевизор карасак та,
Әллә инде күрмибез?

Мыраубикә җанкисәккә
"Вискас" алып бирмибез.
Этебезгә витаминнар
Ашатыйк, дип йөрмибез.

"Сникерс", "Марс"ларның
Кадерләрен белмибез.
Сөтта батмас "Милки уей"ны
Капмаганга көймибез.

Тешебезне саклау өчен
"Орбит" чәйнәп йөрмибез,
Парижский хушбуйларны
Битебезгә өрмибез.

Бигрәк инде ваемсыз без -
Диңгезләрдә йөзмибез.
Багам утравына барып,
Татлы җимеш өзмибез.

"Мерседес"лар, "тойота"лар
Сатып ала белмибез,
Алтыннарга чумар өчен
"Эм-эм-эм"га кермибез.

Урын-җирдә, түшәкләрдә
Шәрә ята белмибез,
Сәяркәләр кочагының
Рәхәт назын күрмибез.

Телевизор күрсәткәнне
Бер сынап карыйм микән,
Песидән элек үземә
Бер "Вискас" алыйм микән?

Рим АЙДАГУЛОВ.

Базарда - базардагыча

...Яшь белмәгәнбез икән,
Кирәк булган бер форсат:
Кешеләргә яшәү өчен
Базар дигән икътисад!

Сәүдәгәрләр тауар сата,
Каранып йөри Гата.
Гаҗәп байларне күреп,
Гата телен шартлата.

Алыпсатар мактап сата
Тауар тулы вагонын.
Юрист агай вөҗдан сата;
Милиция - погонын.

Мулла абзый вәгазь сата,
Фахишә кыз - гәүдәсен.
Менә шундый - шундый базар,
Карагызчы сәүдәсен!

Имансызлар Иман сата,
Сатлык җаннар - ватанын.
Мондый мәхшәр, мондый гыйбрәт
Кайсы илдә бар тагын?!

Ф.ГАЙНИ.
Ютазы районы, Байрака авылы.

Кем эшләми, шул ашый

Хәзер кызык заман китте:
Кем эшләми - шул ашый.
Алыпсатарлар көн саен
Чит илдән тауар ташый.

Күлмәкләр дә, ыштаннар да,
Бияләйләр, беретлар.
Киштәдә сыгылып тора
Иранский оеклар.

Яулык бүген өч мең икән,
Иртәгә алты була.
Бу тауарларның бәясе
Сәгатьләп артып тора.

Эшләгән кеше ашамый
Аптырап башын кашый.
Гаҗәп сәер заман килде -
Кем эшләми, шул ашый!

Рузалия НУРГАЛИЕВА.
Нурлат-Октябрь районы.

Кадерле дуслар!

"Татарстан яшьләре"ндәге язмаларның һәр җөмләсе, һәр сүзе безнең күңел җылысы, авторларыбызның рухи энергиясе белән сугарылган. Без укучыларыбызны яратабыз. Газетаны иҗат итүчеләрнең хәерхаһ мөнәсәбәтен, йөрәк кайнарлыгын сез үзегез дә тоясыздыр дип беләбез. Сездән килгән тәэсирле хатлар, гыйбрәтле язмалар газетаның шифалы йогынтысын тагын да көчәйтәләр.

Газетабыз сезнең өчен шомлы океан уртасындагы тын утрау кебек булсын, җаныгызга сихәт бирсен. Без шуны телибез һәм шуна омтылабыз.

Редакция барчагызга да Яңа елда сәламәтлек һәм бәхет тели!

Кайчан? Кайда? Нәрсә?

Ялдан башланган ел

Халыкның мәш китереп алган елның иң зур бәйрәме әле һаман дәвам итә. Башка еллардагыдан аермалы буларак, быел ял көннәренең исәбе бишкә җитте, ә кайберәүләр өчен 15 көнгә һәм аннан да күбрәккә сузылды. Бу хәл аерым предприятиеләрдә эш күләменең булмавы һәм шуңа бәйле кыскартулар белән аңлатыла. Кайберәүләр, озын-озак ялдан башланган ел гел ялдан гына тормагае, дип тә шаярталар.

Яңа ел хикмәтләре

Яңа елның кибет киштәләренә тәэсире сизелмәле диярлек. Декабрь азагында ирекле сатылган әфлисун, лимон, мандарин һәм алма кебек оҗмах җимешләреннән алып - ит, сөт ризыклары, аракы кебек кандалек товарларга кадәр дефицитка әйләнмәде. Аның каравы кибетләрдә гамәлдән чыгарылган иске вак акчалар урынына яңалары җитешми башлады. Берәүләре моны кибетчеләрнең вак акчаны яшереп тотуыннан күрсә, кибетчеләр үзләре исә халык тимер акчаны үзендә калдырып бара дип раслый. Бу хәлдән чыгу өчен кайбер кибетләрдә иң вак акча берәмлеге итеп шырпы куллана башлады. Дөрес, бер җирдә аның бәясе 5 сум дип билгеләнсә, икенче урында ул тәгәл ун сумга тора.

Милли Мәҗлеснең соңгы сессиясе

1994 елның февралендә Милли Мәҗлес депутатларының вәкаләтләре гамәлдән чыгу сәбәпле II Корылтайга әзерлек эше башланды. Бу уңайдан быелның 7-8 гыйнварында Казанның Укытучылар йортында (Профсоюзлар урамы, 15) беренче Милли Мәҗлеснең соңгы сессиясе үткәрелә. Анда галимнәр, юристлар, икътисадчылар, мәдәният хезмәткәрләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары журналистлары чакырыла.

"Ак барс"ның уңышлы елы


Яңа ел яңа оешкан "Ак барс" банкына уңыш алып килде. Моңарчы беркемнеке дә булмаган Яшьләр үзәге бинасы-аягы белән Татарстан Республикасы милке итеп таныйлды һәм "Ак барс" банкына тапшырылды. Оештыручылары "Татнефть", "Түбән Кама нефтехим", "Свияга", "Татнефтепродукт", "Татавтотранс" кебек зур предприятиеләр булган "Ак барс" акционерлык җәмгыятенең башлангыч капиталы бик зур - 2 миллиард сум тәшкил итә. Башында барыбыз өчен дә мәгълүм Тәлгать Абдуллин торган банк киләчәктә Татарстанның икенче милли банкына әйләнер дип фараз ителә.

Газетаның киләсе саны 11 гыйнварда чыга.

1993 НЕҢ 24 ДЕКАБРЕННӘН 1994 НЕҢ 20 ГЫЙНВАРЫНА КАДӘР "ТЯ"ГА ҺӘМ УКУЧЫЛАРЫБЫЗГА

ЙОЛДЫЗЛАР НИЛӘР ВӘГЪДӘ ИТӘ?

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 - 20.01)



Рөстәм Сабитов - редакциянең 85 ат куәтле машинасының хуҗасы.

Авыр хәлләрдә - сыгылмаучы кыя, башка вакытта - "бал корты", ару-талуны белми, кургашынны алтынга әйләндергәнче тырыша. Сабыр, гадел, яратуын тышка чыгармый торган кырысрак әти. Алдагы ел аның өчен, бер яктан, зуруча активлык һәм нәтиҗәлелек китерсә, икенче яктан, шактый борчулар һәм эреле-ваклы мәшәкатьләр вәгъдә итә. Хәер, мәшәкатьләрнең . күңелле мәшәкатьләр булуы да ихтимал.

СУКОЯРЛАР (21.01 - 19.02)




Рафил Гыйльмиев - газетаның бизәүче рәссамы. **Равил Сабыр** - редакциянең иң яшь журналисты һәм, гомумән, коллективта иң яше.

Фәрештә һәм иблис кушылмасы. Һәрвакыт нинди дә булса яхшылык эшләү ягын карый, нигездә үзенә. Асылын ачып, төбенә төшкәнче бөтен яңа нәрсә аны үзенә тарта. Нечкә хисле, бераз беркатлырак. Нәрсә генә эшләмәсен, кешелеклелек төсмере кертә. Акча аны бөтенләй кызыксындырмый, шуның аркасында Сукоярларның шактые хәерчелектә дөнья куюын да әйтеп үтәргә кирәк.

Февраль уртасында туган Сукоярларны Яңа ел алды ашыгычлыгы төрле көтелмәгән күңелсез хәлләргә китереп кертергә мөмкин. Күптәнге партнер булган кешегез "утыртса" кызмагыз һәм төшенкелеккә бирелмәгез. Урамда алдын-артын карап йөрү хәерле булыр.

БАЛЫКЛАР (20.02 - 20.03)



Рина Зарипова, Гөлсинә Шәмсетдинова, Наилә Баязитова - берсе "Т.Я."нең - хатлар, икенчесе - хаталар, өченчесе акчалар бүлеге хуҗасы.

Үзләреннән гайре бетен кешене дә аңлыйлар. Алар иң тугры һәм бирелгән кешеләр. Балыклар йөрәгеннән дә катлаулырак йөрәк юк - ул бик киң, серле, колачлап булмастай диңгез кебек. Йолдызлар Балыкка күктәге торнага алданып, кулдагы чыпчыкны корбан итмәскә киңәш бирә.

Яңа ел Балыкларның озак исендә калачак. Ел башы тыныч булыр кебек. Әмма артык йомшарып китү дә ярап бетмәс, финанс хәлен төзәтү мөмкинлеген кулдан ычкындырмау мәслихәт булыр.

КУЧКАР (ТӘКӘ) (21.03 - 20.04)

Кызык һәм кызганыч, "Т.Я" гәзитендә бер генә Тәкә дә юк икән. Әмма укучыларыбыз арасында алар җитәрлектер дип уйлыйбыз.

Кучкар, уйлап эш итүгә караганда, күбрәк хис белән яши. Ул соң чиккәчә киңкүңелле була ала, бүләк һәм әмер бирергә ярата. Сукмакны үзе салуны артыграк күрә. Бу билге - башлап йөрүчеләр (пионерлар) һәм уйлап табучылар билгесе. Гыйнварда Тәкәгә ял итү мәҗбүри, ял ук булмаса да, аңа бераз сулыш алырдай шартлар булырга тиеш. Салкын тиюдән, депрессиядән саклану кирәк. "Бар да уза", - дигән җөмләне кабатлап тору да зыян итмәс.

ҮГЕЗБОЗАУЛАР (21.04 -21.05)



Рәис Насыйбуллин, Миңназыйм Сәфәров - икесе дә урын басучылар; берсе - алдым-бирдем буенча, икенчесе - иҗат буенча. **Флюра Низамова** - **Гадел Низам** битлеге астында иң көчле язмалар язып ятучы, **Халидә Минһаҗева** - җаваплы сәркатипнең урынын басучы. **Гөлфия Мөхетдинова** журналистларның таракан язуын күзләре һәм куллары аша үздыручы. О,-о карагыз әле, "Т.Я." гел Үгез һәм Бозаулардан гына тора икән ләбаса!

Тукта, күктәгеләр ни ди болар турында: гадәттә татулык яратадар. түземнәр. Әмма түземлекләре төкәнсә, алардан Ходай үзе сакласын! Алар өчен объективлык мөһим, хәтерләре яхшы, сүзләрендә тора беләләр. Шәхси тормышлары турында сүз чыкканда, сөйләшергә яратсалар да, мыштымнар. Киңкүңелләләр һәм бер үк вакытта бераз комсызлар да.

Алдагы елда күптәнге һәм бүгенге хыяллары чынга ашу ихтималы зур. Гомумән, Яңа елда Үгезбозау күп нәрсәгә ирешәчәк. Зур урынга утыру, җитди отыш уйнап алу, яки инде, һич булмаса, мәхәббәттә уңу ихтималы юк түгел. Ә Үгезбозау өчен кайсы әһәмиятлерәк? Менә бит хикмәт нәрсәдә.

ИГЕЗӘКЛӘР (22.05 - 21.06)



Айрат Салаватуллин - "Т.Я."ның бердәнбер Игезәк сыңары, шуңадыр, бәлки, вазифасының исеме янында "җаваплы" сүзе дә бар, ягъни мәсәлән, җаваплы сәркатип. Ни белән шөгыльләнүен бер Алла үзе генә белә.

Йолдызлар әйтүенә караганда, акыллы, эчкерсез, Меркурий тәэсире астында гел үзгәреп тора, сөйләшергә ярата, курыкмый, йөрәге шәфкатьле. Игезәкләр, бары тик Меркурий тәэсире астында гына булганлыктан, алар кинаягә һәм төрле шаяртуларга, тәнкыйтькә инстинктив рәвештә битараф калалар. Туры килә! Бигрәк тә "тәнкыйтькә битараф" дигән өлеше.

Яңа елны Игезәкләргә яңа танышлыкларын җайга салудан башларга кирәк. Бу - яңа мөмкинлекләр ачу җаен бирәчәк. Алда яңа үрләр көтә, шуңа күрә дә алдан ук һөҗүм хәстәрен күрү сорала.

КЫСЛА (22.06 - 21.07)

Шунысы ачыкланды: "Т.Я."да Кысла юк икән. Кызганыч, әнә бит Йолдыз китабы нәрсә ди: Кысла ярыйсы гына интеллектка ия, хәтере яхшы, ди. Алардагы иркәлек, уйнакчанлык, гашыйкчанлык башка берниндн билгедә дә юк икән. А-у! Бер-ике Кысла, сез кайда, эшкә көтәбез!

Яңа елда, шулай да, Кысланың хыялланган бар нәрсәсе дә тормышка ашып бетмәс. Әмма бу - язмыш арты белән борылды дигән сүз түгел. Бәйрәм булудан файдаланып, бераз ял итеп алу зыян итмәс. Салкын тию куркынычы бар.

АРЫСЛАННАР (22.07 - 22.08)



"Т.Я."ның арысланнары аранда түгел. Ни өчен, чөнки беренче Арыслан **Илсөяр Гарипова** кулына журналистлар өстеннән укучылар язып җибәргән шикаять хатлары турыдан-туры килеп керсә, икенче Арыслан **Әлфия Самат** редакция Рәисен һәм дә бөтен Татарстанның рәисләрен (колхоз, район, оешма һ.б.) дер селкетеп тора, өченче Арыслан фотохәбәрче **Евгений Канаев** кулында да шактый авыр корал бар. Икенче скрипкә Арыслан өчен түгел, ул үзен Галәм үзәге, йолдыз дип саный. Җитәкчелек итәргә, җитәкләп йөртергә, уңыш, әйбер бүләк итәргә, нидән дә булса сакларга-якларга, күңел ачарга ярата. Аларның көче - ышаныч һәм дөреслек.

Яңа елда артык кызып китү һәм сабырсызлык финанс уңышсызлыгына китерүе бар. Акча туздырырга кирәк урында артык сакчыллык күрсәтү дә үзен акламастыр, мөгаен.

КЫЗ (23.08 - 22.09).



Тәкә белән Кысла булмау бер хәл, "Т.Я."да күзгә кырып салырга бер Кыз юк икән бит дисәк, әле шушы көннәрдә генә бер Кызны сайлап алдык. Ул - **Лилия Әхмәтханова** - редакция машинисткасы. Кызлар, алдагы Эт елында күңелегезне төшермәгез! Яңа елда Көчле Абзыйларның көтелмәгән ярдәм кулын күреп, үзегез дә шаккатачаксыз әле.


ҮЛЧӘҮ (23.09 - 22.10).


Узган ел 3.500 гә сатып алган үлчәүне исәпләмәгәндә, редакциядә шулай ук бер Үлчәү дә юк, имеш. Шулай да, безнең язганнарны үлчәүгә салып торучы Үлчәүләрне Яңа елда киеренкелек һәм борчу уйламаган адымнар ясарга этәрүе мөмкин. Уйлап әйтелмәгән бер сүз генә дә күп нәрсәне җимерүе бар. Тигезлек сакларга тырышыгыз, яхшы якка үзгәреш озак көттермәс.

ЧАЯННАР (23.10 - 22.11)

Карары һәрвакыт катгый. Оста саклана белә, әмма көчле ихтыяр һәм үз дигәнендә нык торучанлыгына бәйле рәвештә, беренче булып һөҗүм итми. Эшсөяр, агрессив.

Яңа ел ярыйсы гына тыныч һәм уңай ел булачак. Әмма артык йомшарып китү урынлы булмастыр. Көтмәгән-уйламаган җирдән кинәт гашыйк булу эштә бераз комачаулык тудыруы ихтимал.





Исмәгыйль Шәрәфиев - дилбегәне һәм чыбыркыны тотучы. **Роза Шәрәфиева** - эштән буш араларда Чаян булуы сәбәпле дилбегә тотучыга комачаулавы аркасында чыбыркы ашап торучы, әмма чыбыркы ашатучының үзен рәхимсез рәвештә ашаучы. Фамилиядәшләр, әмма бертуганнар түгел.

Күк бу билгегә тыелгысыз энергия салган. Бу энергияне искитмәгәнлек битлеге каплап тора. Чаян ни теләгәнен бик яхшы белә. Аның холкының асылы - тәвәккәллек. Беркем дә, берниндн шартларда да буйсындыра алмый.

УКЧЫ (23.11 - 21.12).



Фоат Солтанбәков - редакция компьютерларын дәвалаучы бердәнбер башлы кеше.

Моны Йолдызлар да раслый: аек акыл, кискенлек хас Укчыга. Уртакуллылыкны җене сөйми. Артык авыр эшне яратмаса да, сайлап алган хезмәтенә бөтен җаны-тәне белән бирелә.

Яңа елда Укчы кискен үзгәрешләр көтмәсен. Аның хәле әле иң начары түгел. Күпмедер вакытка бераз "суынып" тору да зыян итмәс. Күк күкрәячәген Укчы алдан ук сизәр, давыл аны читләтеп үтәр.

Язмаы Роза ШӘРӘФИЕВА әзерләде.

Янгын сүндерүче композитор

Зиннур Сафиуллин дигән кешене белмәүчеләр булса, берничә җыр исемен атау да җитәдер, мөгаен: "Талларым", "Ак каен", "Бәхет төне"... Былтыр яз көне Казанда узган үзешчән композиторлар ярышында Зиннур, тәҗрибәле авторлар Риф Гатауллин, Илгиз Закиров, Фирзәр Мортазин һәм Ренат Гобәйдуллин белән беррәттән, җиңүче исемен яулаган иде. Жюри әгъзасы, атаклы җырчыбыз Әлфия Афзалова Зиннурның җырларын ишеткәч: "Мин бу егетнең җырларын үз репертуарыма алачакмын!" - дип белдерде хәтта.

Быел көз көне Зиннур Сафиуллин Казанда, Камал театрында зур концерт программасы белән чыгыш ясады. Күптән түгел генә оешкан "Ак каен" исемле үз группасы белән. Әле генә "Раннур" нәшрияты "Сез яраткан җырлар" сериясендә, өч иҗатташы белән беррәттән, Зиннур Сафиуллинның унҗиде җырын бастырып чыгарды. Кыскасы, Әлмәт егете көннән-көн популярлаша бара. Аны көйләр авторы буларак кына түгел, җырчы-башкаручы буларак та таный башладылар.

- Яңа студияң, Зиннур, җырың исеме белән "Ак каен" дип атала. Ул җырың инде күпләргә таныш, ә менә студия дигәне ничегрәк оешты?

- Безнең Әлмәттәге "Татнефть" оешмасы җитәкчесе Ренат абый Галиев идеясе бу. Ул сәнгать яратучы, музыкаль кеше. Аның тәкъдимен "Елховнефть" идарәсе җитәкчесе Ординанд Ногайбәкев күтәреп алды. "Ак каен" бүген шул идарә базасында эшли, ягъни аппаратура, репетицияләр өчен урын, бүтән күп кенә чыгымнар мәсьәләсен алар ярдәмендә хәл итәбез.

- Студиягез бар, димәк, бу син үз группаң белән ныклап торып иҗат итә аласың, яңа җырларыңны эшкәртү, аранжировка ясау, фонограмма яздырту мөмкинлегең бар һәм концертлар белән дә йөрисең дигән сүз, шулаймы?

- Нәкъ шулай Инде өч концерт программам кассеталарга язылган. Җырның көен язу һәм баянда ишеттерү бер нәрсә, ә аны заманча уен кораллары яңгырашына төреп, "ясап" бетерү - икенче нәрсә. Үзем мин музыкаль белем ала алмадым, көйләр башымда гына туа. Дусларым, музыкантлар Михаил һәм Сергей Бердниковлар белән бергәләшеп, ул көйләргә аранжировка ясыйбыз, бизәлешен эшлибез.

- Әлмәт сәхнәсендә сез хәзер - беренче номерлы артистлардыр инде?

- Үземне үзем мактыйсым килми. Дөрес, начар чутта түгелбез бугай инде. Һәрхәлдә, бераз абруй яуларга, хәтта фатир алырга да җырларым ярдәм итте. Югыйсә, биш ел буена хатыным Нәсимә һәм яшь бала белән бер алачык кебек җирдә яшәдек. Хәзер инде икенче улыбыз үсә. Беренчесе, Илназ, укырга керде. Татар гимназиясенә бирдек.

- Быел Казан тамашачысы концертларыгызда күргән нәни артист - ул синең улыңмы инде?

- Юк. Әлегә минеке сәхнәгә чыгарга ояла, аның каравы, дусларымның балалары бик оста, кыю. Программада катнашкан "егет" - ул безнең бригада администраторы Илшат Вәлиуллинның улы Илнур иде.

- Соңгы елларда Әлмәт төбәгеннән күп кенә авторлар, башкаручылар калкып чыкты. Үзара ярышу, конкуренция дигән нәрсә сизеләме?

- Юк. Киресенчә, дусларча, ярдәм итешеп яшибез. Менә, мәсәлән, Рәис абый Нәгыймов, Роберт Андреев - минем дусларым. Марат Туйкин - дустым гына да түгел, ярдәмчем дә. Ул җырларымны редакцияли, газеталар һәм китап өчен әзерләшә.

- Аннары, күп җырларыңның сүз авторлары да нигездә үз якташларың икән әле.

- Шулай булмыйча! Үзебезнең туган яклар, Әлмәт төбәгенең матурлыгын үзебездә яшәүче шагыйрьләрдән дә остарак итеп кем әйтеп бирә алсын? Шуңадыр, мин күбрәк Клара Булатова, Нур Әхмәдиев, Роберт Рәкыйпов, Фоат Садриев, Илдар Хөсни шигырьләрен яратарак төшәм.

- Карале, Зиннур, сине янгын сүндерүче булып эшләгән, диләр. Дөрес сүзме бу?

- Эшләгән дип, мин хәзер дә янгын сүндерүче. Отделение командиры әле хәтта. "Янгын сүндерүче егет" дигән җырым да бар.

- Ай-һай, куркыныч эш! Соңгы арада гына янгыннар сүндерергә туры килгәне бармы соң?

- Зур янгыннардан соңгысы - Чаллыдагы двигательләр заводында булганы.

- Ник, аны сүндерүдә Әлмәт командасы да катнаштымыни?

- Билгеле. Тирә-юнь шәһәрләрдән бөтен көч шунда ташланды. Сүз уңаеннан әйтим: ул безнең Әлмәт янгын сүндерү службасының җитмеш еллык юбилее көннәре иде. Бәйрәмнән ут эченә китәргә туры килде.

- Сезнең эштә иң куркынычы нәрсә?

- Иң куркынычымы? Идән асты катында, подвалда чыккан янгындыр, мөгаен. Былтыргы көздә Әлмәттә бер көндә өч подвал янды. Без килеп җиткәндә, беренче подразделение ут эченә кереп киткән иде. Махсус киемдә, кислород баллоны асып, мин дә подвалга кердем. Кинәт кислород килми башлады. Тотынып кергән трос та кулдан ычкынды. Су кудырта торган җиңсәгә тотынып, көч-хәл белән ишек төбенә килеп җиткәнмен дә, һушымны югалтып егылганмын. Кыскасы, төрле хәлләр була инде, кайчагында, янып бетеп, өскә түбә ишелеп төшә...


- Зиннур, сиңа теләк шул: утялкын күбрәк иҗатыңда булсын!

- Рәхмәт.

Ялкынлы җырлар авторы белән
Гадел НИЗАМ сөйләште.

Бәхет төне


Зиннур САФИУЛЛИН көе,
Нур ӘХМӘДИЕВ сүзләре.
Марс КӘШИПОВ эшкәртүендә.



Каеннары, ай-һай, ак икән,
Сөю белән тулы чак икән,
Каеннардан якты моң тама.
Бу бит бәхет төне,
Эзлә бәхетеңне,
Юк, йоклама, егет, йоклама.

Егет яна кызга күз атып,
Сандугачлар йөри озатып,
Йолдызлардан энҗе сибелә.
Табышалар парлар,
Кавышалар ярлар,
Юк, бәгърем, юк бит син генә.

Бәхет төне узып китәрме,
Безгә бәхет биреп китәрме?
Каеннардан сора, каеннан.
Күңелемнең күркен
Яулый алмас беркем -
Исемнәрең каеп язылган!



Кышкы Казан.



Е.КАНАЕВ фотолары.

Безнекеләр иң җитезләр, иң көчлеләр

Күптәннән килгән матур гадәт буенча ел ахырында спорт турында язучы журналистлар елның иң оста спортчыларын билгелиләр. 1993 елда безнең егетләребез һәм кызларыбыз дөнья күләмендә булсын, Европа, Русия беренчелегендә булсын, йөзгә кызыллык китермәделәр.

Исемлектә беренче урынны бик хаклы рәвештә стендта ату остасы, атказанган спорт мастеры Светлана Демина (Казан) алып тора. Ул үзе катнашкан һәр бәйгедән - денья, Европа, Русия чемпионатларыннан алтын медальләр алып кайтты. Түбән Камадан ирекле көрәш остасы булган тагын бер кызыбыз - Лилия Исламова мактала. Ул Русия һәм Европа чемпионы булды, дөньяда иң көчлеләр арасына керде.

Гер күтәрү буенча дөнья чемпионы Фәнис Сәләхиев турында сез ишетеп беләсез инде. Хәзер Кукмарада яшәүче бу егет дөнья беренчелегендә үз үлчәвендә иң оста күтәрүче булып кына калмады, ә шундый мәртәбәле ярышта беренче тапкыр җөмһүриятебез әләмен дә күтәртте, гимныбызны яңгыратты.

Чаллыдан ерак араларга йөгерүче Елена Маскина Русия чемпионы булды, дөньякүләм ярышларда дүртенче урынга чыкты.

Академик ишү остасы Александр Устинов (Казан) өчен дә уңышлы булды 1993 ел. Дөнья беренчелегендә көмеш медаль оту, халыкара турнирларда алдан килү аны Олимпия җыелма командасына кертте.

Самбочы Вадим Волков быел бик күп көндәшләрен аркаларына салды, зур-зур ярышлардан медальләр алып кайтты. Баулыдан гер күтәрүче Иван Стекольников дөнья беренчелегендә бронза медальгә лаек булды.

Җиңел атлетиканың өчле сикерү төрендә чыгыш ясаучы Казан егете Денис Капустин дөнья беренчелегендә алтынчы урынны алды, бу төрдән иң көчлеләр арасында йөрде.


Әлмәттән чаңгычы Ольга Данилова шулай ук Олимпиадага баручы Русия җыелма командасына кандидат булып тора.

Иң көчлеләр арасында Русия беренчелегендә унынчы урынны яулаган "КамАЗ" футбол командасы (тренеры В.Четверик) да бар.

Күреп торабыз: республикабызның иң көчле атлетлары спортның бик күп төрләре буенча чыгыш ясыйлар һәм географиясе дә киң.

Татарстан Дәүләт физкультура һәм спорт комитеты алардан тыш шахмат композицияләре төзү буенча дөнья чемпионы Леонид Ярошны, халыкара гроссмейстер Илдар Ибраһимовны, ветеран чаңгычылар арасында дөнья чемпионкасы Асфира Гайфуллина һәм Русия футбол чемпионатының иң оста һөҗүмчесе Виктор Панченконы да бүләкләде.

А.ГАФИЯТОВ.



Сез бәхетле иттегез

Кадерле редакция! Сезнең газетадан "Җирдә күпме җаннар йөри иясез шатлык булып..." дигән язманы укыгач, язарга теләк туды. Рәхмәт язам мин Сезгә. Танышулар, табышулар, аннан да бигрәк бер-береңне ошатышулар җиңел түгел. Дөрес әйтәсез. Ләкин шул 100 кеше арасыннан берәү генә үз бәхетен тапса да, бу бит зур куаныч. Менә без ирем белән кайчандыр сезнең абонентларыгыз идек. Без хәзер законлы никах белән теркәлгән ир белән хатын, гаилә булдык. Рәхмәт Сезгә! Кайчандыр мин үз тиңемне табарга хыяллана идем, ә хәзер хыялым чынга ашты. Бу Сезнең ярдәм белән.

Барыгызны да Яңа ел белән котлап, тагын бер кат рәхмәт белән

Галия һәм Илдус ХАФИЗОВЛАР. Түбән Кама.

Алдыгызда баш иям

Мин үзем Туймазы районының Бәйрәкә-Түбә авылыннан. Алты бала үстек. Шулай да авырлыкларны белмәдек. Әтием белән әнием бик тырыш кешеләр иде. Авылыма кайтсам, алар турында ишеткән җылы сүзләр миңа яшәргә көч-дәрт бирә. Алар күптән инде гүр ияләре, авыр туфраклары җиңел булсын. Язасы килгән сүзем авылдашларым турында. Ык елгасы буена урнашкан авылымның талларына сокланмаган кеше юктыр. Аның кешеләренә дә сокланмаган кеше юктыр, дип уйлыйм. Унбер ел элек әнием, бик озак чирләп, үлеп китте. Мин ул вакытта яшь бала белән ялда идем, өч ай аның янында булырга туры килде. Нинди генә ярдәмнәр итмәделәр авылдашларым безгә, кем ничек булдыра ала, бер минутка да ташламадылар. Сезнең җылы сүзләрегез, киңәшләрегез һәрчак минем белән.

Бу вакыттан соң күпме сулар аккан, күпме югалтулар кичерелгән. Әниебездән соң әтиебез, аннан соң апабызны югалттык. Сентябрьдә зур абыем Ык елгасына төшеп юк булды, гәүдәсен дә таба алмадык.

Әнием безне авылның ирләренә - абыем, киленнәренә - җиңгәм дип дәшәргә өйрәтте. Күпме булыштыгыз сез безгә, авылдашлар, кайгыбызны уртаклаштыгыз, юаттыгыз, бергә елаштыгыз, безнең белән бергә төн димичә көн димичә, ял итмичә янәшәбездә булдыгыз. Авылымның һәр кешесен исемләп чыксам, кәгазь җитмәс. Ишетәсезме мине, авылдашларым! Сезнең алдыгызда мин баш иям, рәхмәтләр укыйм.

Йөрәк ярсуларын басарга сездән генә көч, сабырлык ала алырмын кебек, авылдашларым, туганнарым!

Нәсыйха МИРЗАҺИТОВА. Түбән Кама.

Иң сөйкемле ханым

Балтач "Сельхозтехника"сында сәркатибә булып эшләүче Ризада ханым турында сүзем. Бу һөнәр кешеләре турында мактау сүзләре ишетергә өйрәнелмәгән. Әмма Ризада ханым бүтән исемлектә дияр идем. Ул һәр кергән кеше белән ягымлы итеп сөйләшә, аңлата, аның йомшак сүзе йөрәккә май булып ята. Беркайчан беркемгә караңгы чырай күрсәтмәс. Зәвык белән киенә белүче бу ханымның әле дә булса яшь кызлар кебек зифа буй-сынына карап сокланмаган кеше юктыр. Менә сәркатибәләр ничек булырга тиешләр. Мин аны Яңа ел белән чын күңелдән котлар идем.

РӨСТӘМ.



- Син нигә дәреслек битләрен ертасың? - дип сорыйлар Галидән.
- Мин бит укылган битләрне генә ертам.
- Ник?
- Ялгышып тагын бер кат укымас өчен.

* * *

Купеда ике ханым белән бер солдат бара. Кич житкәч солдат итеген салып, аяк чолгауларын әскә киштәгә элеп куя. Купега чыдап булмаслык сасы ис чыга.

- Солдат, син аяк чолгауларыңны алмаштырасыңмы? - ди ханымнарның берсе, нәфрәтләнеп.
- Юньле әйбергә булса алмаштырам! - ди солдат.

* * *

- Доктор, зинһар өчен, яшермичә, чын дөресен әйтегез... Авыр булса да түзәрмен. Кулларыннан гипсны салдыргач минем ирем савыт-саба юа алачакмы?

* * *

Авыл крәстияне - шәһәрдән килеп төшкән аучыга:
- Моннан өч чакрым төньяктарак урман буенда мин бүре эзләре күрдем.

Аучы:
- Ә кая монда коньяк?

* * *

Хатыны - иренә:
- Синен бер меңлек акча күргәнең бармы?
- Бар.
- Ә илле меңлек.
- Анысын да бар.
- Ә изелеп беткән миллион?
- Андые да буламыни?
- Була. Ышанмасаң, гаражга чыгып кара.

* * *

- Әти, киногa барыйм әле?
- Ярамый! Өченче көн сиңа кызамык прививкасы ясадылар, кичә тешеңне суырдылар, ә бүген киногa бармакчы буласың. Өч рәхәт бергә килмиүл!

* * *

Газетада хәбәр:
"Кичә 17 нче балалар тудыру йортында 45 яшьлек Мәүлидә Шакирова иртәнге сәгать сигездә биш игезәк кыз бала тапты. Врачлар аның ире Гали Шакировның тормышын саклап калып булыр дип өметләнәләр".

* * *

- Сөенче, Луиза! - ди әтисе кызына. - Эдуард синең кулыңны сорады.
- Бик яхшы, тик минем бер дә әнидән аерыласым килми.
- Анысы бар шул, кызым. Хәер, кайгырма, әниеңне үзең белән алып китәрсең.

* * *

Сырхауханәдә иртәнге тикшерү.
- Сезнең нәрсә?
- Геморрой.
- Ничек дәвалыйлар?
- Трубка тыгалар да порошок сибәләр.
- Зарыгыз бармы?
- Юк.
- Ә сезнең нәрсә?
- Тамак авырта.
- Ничек дәвалыйлар?
- Трубка тыгалар да порошок сибәләр.
- Зарыгыз бармы?
- Зар түгел, үтенеч: теге трубканы башта минем тамакка тыксыннар иде.

* * *

Ике скелет очраша:
- Син кайчан үлдең: икътисадый реформа беткәнчеме, аннан соңмы?
- Аннан соң. Ә син?
- Ә мин әле үлмәгән.

* * *

Авыру теш врачы кабинетына керә. Аны күрү белән врач елмаеп җибәрә.
- Ә-ә, әйдәгез, әйдә! - ди ул, кояш кебек балкып. - Хәтерем ялгышмаса, билетың юк дип кичә миңа штрафны сез салган идегез бугай. Бер дә кыенсынмагыз, креслога ныграк тотынып утырыгыз...

* * *

Укытучы:
- Иң соңгы булып кешенең авызында нинди теш чыга?

Укучы:
- Ясалма теш.

* * *

- Вәли, синең әниең нигә көне буе урын өстендә ята? Авырыймыни?
- Юк. Торып китсә, әти караватны сатып эчәр дип курка.

* * *

- Нишләргә инде миңа хәзер? Ничә кыз алып кайтып күрсәттем, берсе дә әнигә ошамый.
- Ә син аңа охшаган кыз тап.
- Тапкан идем. Аны күргәч, әти кара тавыш чыгарды.

ТЯ

Баш мөхәррир
Исмәгыйль ШӘРӘФИЕВ
(53-52-34)

ЯЗЫГЫЗ:
420066, Казан, Декабристлар урамы,2.
"Татарстан яшьләре"

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:
53-07-52 - баш мөхәррир урынбасары
53-07-54 - җаваплы сәркатип, реклама
53-07-58 - хатлар бүлеге
53-07-54 - тәрҗемә
53-07-56 - сәясәт, мәдәният-сәнгать
53-07-52 - авыл хуҗалыгы, экология
53-07-50 - рәссам, компьютер операторлары.

"Татарстан яшьләре"н гамәлгә куючылар - Татарстан Республикасының Яшьләр оешмалары советы, Татарстан Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы, редакциянең хезмәт коллективы.

Газета Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 268-нче номерлы таныклык белән теркәлде.

"Т.Я" сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Реклама һәм белдерүләрдәге мәгълүматларның дөреслеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы.

Редакциянең исәп-хисап счеты:
Р/с 700161998/700751 ВКАБ РКЦ ГЦБ г.Казани, МФО 265005
Индекс - 54121
Тираж - 200000

Татарстан газета-журналлар басмаханәсе.

Газета басылуга кул кую график буенча 15 сәгатьтә. Бу санга 15 сәгатьтә кул куелды.

Заказ 6190